**РЕШЕНИЕ (КАРАР)**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге составына керүче Кили авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**14 ноябрь 2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кили авылында гражданнар җыены беркетмәсе 2020 нче елның 14 нче ноябрендә түбәндәге сорауга тезелде:

"100 % күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, ялгыз яшәүче, балалары булмаган 70 яшьтән узган өлкәннәрне исәпкә алмаганда, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Кили авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2021 нче елда үзарасалымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы:

- Г.Тукай урамы буенча урнашкан балалар мәйданчыгы өчен киртәләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Новая урамына янгынга каршы гидрант урнаштыру һәм аңа комплектлау җихазлары сатып алу;
- җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән тротуарларны урнаштыру".

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучылар исемлегенә 261 граждан кертелгән;
җыенда 152 граждан катнашты.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен 152 граждан тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кили авылында гражданнар җыенын гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча уздырылды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кили авылында гражданнар җыены карарын түбәндәге сорау буенча кабул итәргә: "100 % күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, ялгыз яшәүче, балалары булмаган 70 яшьтән узган өлкәннәрне исәпкә алмаганда, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Кили авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2021 нче елда үзарасалымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- - Г.Тукай урамы буенча урнашкан балалар мәйданчыгы өчен киртәләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Новая урамына янгынга каршы гидрант урнаштыру һәм аңа комплектлау җихазлары сатып алу;
- җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән тротуарларны урнаштыру".

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе

Шарипҗанов Р.Н.